## I.3. СҮЗ БАШЫ

Русча-татарча-инглизчә-төрекчә тематик сүзлек 7 000 нән артык сүз һәм сүзтезмәне үз эченә алган 231 тематик төркемнән гыйбарәт. Сүзлектә көндәлек тормышта аралашу, уку һәм язу өчен кирәкле сүзләр тупланган, шулай ук тематик төркемнәрне тулыландыра торган өстәмә лексика кертелгән. Барлык сүзләргә дә сүзтезмә яки җөмләләр рәвешендә мисаллар китерелгән.

Сүзлек рус, татар, инглиз һәм төрек телләрен өйрәнүчеләргә һәм укытучыларга, шулай ук әлеге телләр буенча белемнәрен камилләштерергә теләүчеләргә тәкъдим ителә. Сүзлекне куллануның кайбер мөмкинлекләре белән III.2 (рус телендә) һәм III.3 (татар телендә) бүлекләрендә танышырга мөмкин.

Сүзлекне әзерләгәндә, төрле юнәлештәге бертелле һәм икетелле сүзлекләр төзү тәҗрибәсе исәпкә алынды. Сүзлекнең рус телендәге өлешенең нигезенә бертелле һәм икетелле тематик сүзлекләр, аерым алганда, тематик сүзлек-минимумнардагы материаллар салынды (кулланылган чыганаклар исемлеген III.4 бүлектә карагыз).

Басма кереш өлеш, сүзлек һәм кушымтадан тора.

Кереш өлеш (I) үз эченә түбәндәге бүлекчәләрне ала:

○ «Сүз башы» (рус телендә – I.1; татар телендә – I.3); монда белешмәлеккә гомуми характеристика бирелгән;

○ «Тематик сүзлекнең төзелеше» (рус телендә – I.2; татар телендә – I.4); биредә белешмәлекнең составы, сүзлек мәкаләләрен төзү үзенчәлекләре тасвирланган.

Сүзлек өлеше (II) дүрттелле тематик сүзлекне үз эченә ала.

Кушымтада (III) түбәндәге бүлекчәләр бирелгән:

○ «Шартлы билгеләр һәм кыскартулар» (III.1);

○ «Сүзлекне куллану мөмкинлекләре турында» (рус телендә – III.2.; татар телендә – III.3);

○ «Кулланылган чыганаклар» (III.4).

Форзацларда тематик классификацияләүнең гомуми планы урнаштырылган: а) рус һәм татар телләрендә (алгы форзацта); ә) инглиз һәм төрек телләрендә (арткы форзацта).

Әлеге сүзлеккә нигезләнеп, электрон тематик сүзлек эшләнә, ул «Сүзлекләрнең электрон фонды» сайтына урнаштырылачак (https://www.suzlek.antat.ru).